| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**СОВЕТ ПСЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2020 елның 3 августыннан** **№ 156**

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлеге территориясен
төзекләндерү, тиешле тәртиптә тоту,
җыештыру, чисталыкны тәэмин итү һәм
тәртипкә китерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр
кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советының 2018 елның 5 мартында кабул ителгән 69 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү, тиешле тәртиптә тоту, җыештыру, чисталык һәм тәртип кагыйдәләрен раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге территориясен төзекләндерү, тиешле тәртиптә тоту, җыештыру, чистарту һәм тәртипкә китерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 3 өлешкә «Песәй авыл җирлегенең торак пунктлары территорияләрен карап тоту» түбәндәге эчтәлекле 3.11 пункт өстәргә:

«3.11. Җир кишәрлекләрен Сосновский балтырганыннан арындыру буенча чаралар.

3.11.1. Җир кишәрлекләренә хокукчылар үзләренең милкендәге, билгән яисә файдаланган җир кишәрлекләрен Сосновский балтырганыннан арындыру буенча чаралар үткәрергә тиеш. Сосновский балтырганын юк итү буенча чаралар аның чәчәккә бөреләнгәнче һәм чәчәк ата башлаганчы үткәрелергә тиеш.

Сосновский балтырганыннан арындыру буенча чаралар түбәндәге ысуллар белән үткәрелергә тиеш:
химик - чабу, коры үсемлекләрне урып-җыю, тамырларын алып ату;
механик - чабу, коры үсемлекләрне урып-җыю, тамырларын алып ату;
агротехник - туфрак эшкәртү, күпьеллык үләннәр чәчү.»

2. Әлеге карар Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый

мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырылу юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Песәй авыл җирлеге<br>Советы Рәисе В.И. Мөхәммәтгалеев